**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

11.07.2022 594-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 211-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 2 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 мартындагы 211-п номерлы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2019 елның 25 февралендәге 176-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.5 пунктында 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнештә норматив хокукый актны (норматив хокукый акт проектын) бәяләү;».

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр вазыйфаларын башкаручы А.М.Шиһапов

Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы А.И. Ткачук